ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«24» марта 2023 г.

**КАРАР**
№6

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру , кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 №7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасының 28.07.2004 №45 законы- «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» ТРЗ, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 №2314 «Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган, яктырту җайланмалары, электр лампалары җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында" карары нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренче җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында» 28.12.2021 №32 карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуван авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән ттерекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләргә: гараж территориясендәге торак булмаган бина: Арбаш авылы, Х.Такташ урамы.

3.Күпфатирлы йортларның милекчеләре, ялланучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучы гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау, тиешенчә җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру урыннары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең яктырткыч җайланмалар, электр лампалары җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү турындагы 28.12.2020 2314 нче карарының 4 пункты белән расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннары, шул исәптән терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә, алар күпфатирлы йортларда милекчеләр, яллаучылар, биналардан файдаланучылар

булып торсалар, әгәр бу күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса туплау урыннарын оештырырга.

5. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның (урыннарның) урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый (pravo.tatarstan.ru) мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы

Карадуган авыл җирлеге башлыгы Ш.В.Низамиев